**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

04.10.2021 № 72

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы уставы нигезендә, 2021 елның 7 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәләрен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының « Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 7 сентябрендәге бәяләмәсен исәпкә алып, карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга..
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегенә территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru/)
3. Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге советына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында элегрәк кабул ителгән карарның үз көчен югалтуын таныйрга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы Рәисе Г.Г.Хәкимов